# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«06» 05 2019 ел Яр Чаллы № 52

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге Суровка авылында «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линия объектын планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 28 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегендә «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линия объектын планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Халык тыңлауларын бер көндә, 2019 елның 10 июнендә 15.00 сәгатьтә, түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Яңа Троицкий авылы, Ленин урамы, 16Б, Яңа Троицкий авыл җирлеге Башкарма комитеты.
3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы баш архитекторы А.Н. Нәдершинны билгеләргә.
4. Гражданнарның катнашу һәм проект буенча фикер алышу тәртибен кушымтадагыча расларга.
6. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының
2019 елның 06.05
52 санлы карарына кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегендә «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линия объектын планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм район гражданнарының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.
2. Проектның график һәм текст материаллары Яңа Троицкий авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, мәгълүмати стендларда урнаштырылган.
3. Проект буенча материаллар белән танышу вактыты: дүшәмбе – җомга, 9.00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).
4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга тиеш.
5. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 8 маеннан 2019 елның 8 июненә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.
6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.
7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.
8. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.
9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
   - чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
   - проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр;
   - фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.
10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.
11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме;
- халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;
- халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул мәҗбүри рәвештә халык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.